ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Җәмәгатьчелек вәкилләре кандидатураларына таләпләр**

1. 35 яше тулган, югары юридик белеме булган, үзенең яман атын чыгарырлык гамәлләр кылмаган, дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны, дәүләт яисә муниципаль хезмәт урыннарын биләмәгән, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре, адвокат һәм нотариус булмаган Россия Федерациясе гражданнары җәмәгатьчелек вәкилләре итеп билгеләнеп куелырга мөмкин.

2. Җәмәгатьчелек вәкиленең чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булырга тиеш түгел.

3. Чит ил агентлары реестрына кертелгән зат җәмәгатьчелек вәкиле була алмый.»;

2) 4 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктка «, чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алуы йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алуы» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) җәмәгатьчелек вәкиленең чит ил агентлары реестрына кертелүе.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 05 март
№ 12-ТРЗ